**ГЛАВА СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**18.09.2017 г.** **с.Соболевское** **№ 6**

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., 20 ст. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 1 п.1 пункты, Соболевский авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

Карар бирәм:

1. Соболевский авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләре буенча уртак инициативасын чыгарырга:

«2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчалар юлламасы белән риза булырсызмы:

- Соболевский авыл җирлеге территориясендә урнашкан халыкны су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау һәм реконструкцияләү - 70 050,00 сумга

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н. Майорова